**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Азнакай шәһәр тибындагы бистә Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.б. №7 «15» май 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе Советының 2012 елның 21 мартындагы 8 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (17.10.2012 № 33, 30.09.2013 № 27, 28.05.2014 № 21, 13.12.2016 № 23 карарлар редакциясендә)

Җирле үзидарә турындагы Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә һәм Азнакай шәһәр прокурорының Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе Советының 2012 елның 21 мартындагы 8 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставының (17.10.2012 № 33, 30.09.2013 № 27, 28.05.2014 № 21, 13.12.2016 № 23 карарлар редакциясендә) кайбер нигезләмәләргә каршы чыгуын исәпкә алып,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Азнакай шәһәр тибындагы бистә Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе Советының 2012 елның 21 мартындагы 8 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (17.10.2012 № 33, 30.09.2013 № 27, 28.05.2014 № 21, 13.12.2016 № 23 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 46 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9 пунктны өстәргә:

«9. Террорчылыкка каршы көрәш өлкәсендә:

- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү өлкәсендә муниципаль программалар эшлиләр һәм гамәлгә ашыралар;
- җирлектә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәүне формалаштыру, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү буенча мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыралар һәм үткәрәләр;
- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган чараларда катнашалар;

- муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәләр;
- террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына җибәрәләр;
- террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.
1.2. 46 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын 10 пункт дип санарга.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиева